Р Е С П У Б Л И К А Т А Т А Р С Т А Н
**Исполнительный комитет Янгасалского сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

Т А Т А Р С Т А Н
Р Е С П У Б Л И К А С Ы
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**Янасала авыл жирлеге башкарма комитеты**

---

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**« 11» декабрь 2025** **№ 19**

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының "Яңасала авыл җирлеге" муниципаль берәмлеге территориясендә йорт хайваннары йөрү урыннарын билгеләү турында

«Хайваннар белән җаваплы эш итү турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 2018 елның 27 декабрендәге 498-ФЗ номерлы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә йорт хайваннарын тотуга, шул исәптән аларны йөртүгә карата өстәмә таләпләрне раслау турында» 2023 елның 11 августы № 971нче карары нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Яңасала авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы белән, гражданнарның, хайваннарның иминлеген, физик һәм юридик затларның мөлкәтен саклауны тәэмин итә торган йорт хайваннарын йөртү өчен шартлар тудыру максатларында, Яңасала авыл җирлеге башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Йорт хайваннарын йөртү өчен рөхсәт ителгән урын (урыннар) итеп билгеләргә:
- Яңасала авыл җирлегенең торак секторларыннан читтә гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләре.

2. Әлеге карарны түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә:
- ТР, Кама Тамагы районы, Яңасала авылы, Үзәк урам, 1;
- ТР, Кама Тамагы муниципаль районы, Шәпкә авылы, Клуб урамы, 14

һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.Х.Шигабеев